| ГЛАВА СОВЕТА СТАРОТЯБЕРДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ТӘРБИТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12 август, 2022 ел Иске Тәрбит ав. № 1

Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлегенең Иске Тәрбит торак пунктында урнашкан Төньяк урамының 1 нче йорттан алып 10 нчы йортка кадәр өлешен Алмаз Батанов урамына үзгәртү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25, 56 статьясы, «Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карары, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске Тәрбит авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР ИТӘМ:

1. 2022 елның 22 августында 11 сәгатькә Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Иске Тәрбит авылы, Совет ур., 28 адресы буенча Иске Тәрбит КФҮдә Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлегенең Иске Тәрбит торак пунктында урнашкан Төньяк урамының 1 нче йорттан алып 10 нчы йортка кадәр өлешен Алмаз Батанов урамына үзгәртү мәсьәләсе буенча ***гражданнар җыены*** билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлегенең Иске Тәрбит торак пунктында урнашкан Төньяк урамының 1 нче йорттан алып 10 нчы йортка кадәр өлешен Алмаз Батанов урамына үзгәртергә ризамы?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Иске Тәрбит авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске Тәрбит авыл җирлеге рәсми сайтында урнаштырырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык Тимофеев В.Г.

Совет Старотябердинского сельского поселения
Иске Тәрбит авыл җирлеге Советы
ИНН 1621000534